КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 октябрь г.Казань № 793

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәтен компенсацияләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү турындагы мәгълүматны «Социаль өлкәдә ярдәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны тәэмин итәргә. Әлеге мәгълүматны «Социаль

өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны (аннан алуны) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 2025 елның 1 ноябренә кадәр әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

7. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар 2025 елның 1 ноябреннән (әлеге карарның рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган әлеге карарның 4 пунктыннан тыш) үз көченә керә;

бу карарның гамәле 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 6 октябрь, 793 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча күпбалалы гаиләләрдән балаларны укыту кыйммәте өчен, алар көндезге бүлектә белем алу шарты белән, 30 процент күләмендә компенсация (алга таба – һөнәри белем бирү оешмасы, компенсация) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Компенсация алу хокукы күп балалы гаилә составына кергән, һөнәри белем бирү оешмасы белән килешү төзегән, 23 яшькә кадәрге балигъ булган белем алучыга яки күп балалы гаилә составына кергән, һөнәри белем бирү оешмасы белән күп балалы гаилә составына керүче балигъ булмаган балага карата килешү төзегән ата-ананың (уллыкка алучыларның) берсенә (алга таба – гариза бирүче) бирелә.

Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында күпбалалы гаилә дигәндә гаилә составында өч һәм аннан күбрәк, олы баласына 18 яшь яки белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән 23 яшь тулганга кадәр балалары (тәрбиягә алган балаларны кертеп) булган гаилә аңлашыла.

Белем бирү хезмәтләре өчен фактта түләү гариза бирүченең гаилә әгъзасы тарафыннан башкарыла.

Гариза бирүче исеменнән гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәдә вәкаләтләре билгеләнгән затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле) булырга мөмкин.

3. Компенсация гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычы булмау шарты белән бирелә.

4. Белем бирү оешмаларында ике һәм аннан күбрәк баласы укыган очракта, компенсация күп балалы гаиләнең һәр баласына бирелә.

5. Компенсация һөнәри белем бирү оешмасында уку өчен фактта түләнгән бәясенең 30 проценты күләмендә бирелә.

6. Ана (гаилә) капиталы акчасы (аның бер өлеше) белем алу өчен тотылган очракта, компенсация ана (гаилә) капиталы акчасы (аның бер өлеше) күләменнән артып киткән, уку өчен фактта түләнгән бәясе өлешендә бирелә.

7. Компенсация билгеләү гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекләре (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Компенсация билгеләү өчен гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле Үзәк бүлегенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, гариза бирүченең банкта яки башка Россия кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, ткомпенсация билгеләү турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра, аңа түбәндәгеләрне терки:

һөнәри белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында шартнамә күчермәсе;

гариза бирүче яки аның гаилә әгъзасы тарафыннан башкарылган, һөнәри белем бирү оешмасында уку өчен фактта түләүне раслый торган документлар күчермәләре;

баланың һөнәри белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча уку фактын раслый торган документ күчермәсе;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары күчермәсе – Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү булмаганда;

гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, ышанычнамә күчермәсе.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле вәкиле Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документын күрсәтә.

9. Гариза һәм компенсация билгеләү өчен кирәкле документлар, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы) файдаланып, электрон рәвештә (техник мөмкинлек булганда)җибәрелергә мөмкин; алга таба гаризага теркәлгән документларның төп нөсхәләре гариза теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә Үзәк бүлегенә күрсәтелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша гариза бирү гади электрон имза кулланып башкарыла.

10. Гариза һөнәри белем бирү оешмасында уку чорында бер тапкыр бирелә.

Компенсация бирү һөнәри белем бирү оешмасында уку өчен фактта түләнгән һәм әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар (документларның күчермәләре) тапшырылганнан соң, әмма баланың һөнәри белем бирү оешмасында укуы тәмамланган календарь елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

11. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә, компенсация билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү факты турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

никахлашуны дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булу (булмау) турында;

опека (попечительлек) билгеләү турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында;

Россия Федерациясендә күп балалы гаилә статусын билгеләү турында.

12. Үзәкнең бүлекчәсе гариза теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә компенсация билгеләү яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр:

әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталыннан файдаланып электрон документ рәвешендә бирелгән булса, әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны, шул исәптән гариза теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә тапшырмау;

гариза бирү датасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибе турында» 2024 ел, 17 октябрь, 893 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә күпбалалы гаилә статусын раслый торган таныклык бирү тәртибенең 4 пунктында билгеләнгән гариза бирүченең гаилә составына карата таләпләрне үтәмәү;

бала Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан һөнәри белем бирү оешмасында белем алу;

гариза бирүче тарафыннан компенсация алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактын ачыклау;

гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычлары булу;

һөнәри белем бирү оешмасында уку тәмамланганнан соң гариза белән мөрәҗәгать итү.

Компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән булса, гариза бирүче, баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләр бетерелгәннән соң, Үзәк бүлегенз кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Компенсация бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән срок чыкканнан соң тапшыру;

гариза бирүченең үлеме;

гариза бирүче Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәү урынына күчену;

гариза бирүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычлары булу.

14. Гариза бирүчеләрнең банкларда һәм башка Россия кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына компенсация күчерү «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан компенсация билгеләү турында карар кабул ителгән айдан соң килә торган айның 25енә кадәр гамәлгә ашырыла.

15. Гариза бирүче компенсация бирүнең туктатылуына китерә торган хәлләр барлыкка килгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Үзәк бүлегенә шундый хәлләр турында хәбәр итәргә тиеш.

16. Гариза бирүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алардагы документларның төп нөсхәсе өчен җавап бирә.

Нигезсез алынган компенсацияне кире кайтару гариза бирүче тарафыннан ирекле рәвештә башкарыла, әгәр гариза бирүче ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартса, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

---